ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 540 31 август 2017 ел

## Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләү билгеләү турында» 2017 елның 29 июнендәге 405 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексының 154 һәм 156 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләү билгеләү турында» 2017 елның 29 июнендәге 405 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 3 һәм 4 пунктларын 2017 елның 1 сентябреннән үз көчен югалткан дип танырга.

2. Түбән Кама муниципаль районының идарәче компанияләренә Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 9.2 һәм 9.3 пунктларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Карарны «Нижнекамская правда» һәм «Туган як» газеталарында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Г. Сәйфетдинов